■ Кыйсса

# ӨЧ НӘСЫЙХӘТ

Локман хәким үзенең углына нәсыйхәт итте:

- И улым! Яхшылар нәсыйхәтеннән баш тарта күрмә, һәрни нәсыйхәт әйтсәләр дә, кабул итүче бул.

Көннәрдән бер көнне Локманның углы берничә яраны белән сәфәргә чыгып барганда, бер юл аермасында бер кеше әйтте:

- Кем дә булса миңа мең тәңкә бирсә, ул кешегә бер нәсыйхәт өйрәтермен, - диде.

Локман хәкимнең яраннарыннан берсе әйтте:

- Әйдә, өйрәт! - диде.

Ул кеше әйтте:

- Башта мең тәңкәне бир, аннан соң әйтәм.

Локманның углы:

- Ул мең тәңкәне мин ул нәсыйхәткә тотам, ни өйрәтсәң дә өйрәт, - диде.

Ул кеше әйтте:

- Тәңкәләрне бир, аннан соң өйрәтермен.

Шулай итеп, Локман хәкимнең углы мең тәңкәсен бирде. Аннан соң ул кеше әйтте:

- Берәр кеше синнән сораса: “Бу ике нәрсәнең кайсы яхшырак?” - дип, ул хәлдә аңа әйт: “Күңелең кайсын теләсә, шунысы яхшырак”, - диген.

Локманның углы сорады:

- Нәсыйхәтең шул гынамы?

Нәсыйхәтче:

- Әгәр нәсыйхәтемне саклап тотар булсаң, бу да күп булыр, - диде.

Угыл белән юлдашлары юлларын дәвам иттеләр. Бара торгач, бер шәһәргә җиттеләр. Урам башында торган берәү боларга әйтте:

- Кем дә булса миңа мең тәңкә бирсә, аңа бер нәсыйхәт өйрәтермен.

Локманның углы тагын әйтте:

- Ул мең тәңкәне мин тотармын, ни әйтерсең?

Нәсыйхәтче әйтте:

- Башта тәңкәләрне бир, аннан соң өйрәтермен.

Локманның углы тагын тәңкәләрен бирде. Ул кеше өйрәтте:

- Кемнең дә булса нигъмәтләреннән авыз итсәң, аның кадер-хөрмәтен танучы, ризык хакын саклаучы бул.

- Нәсыйхәтең шул гынамы?

Аннан соң янә киттеләр. Шәһәрнең бер урамында тагын бер нәсыйхәтче әйтте:

-Кем дә кем миңа мең тәңкә бирсә, аңа бер нәсыйхәт өйрәтермен.

Локман хәкимнең углы мең тәңкәсен бирде, ул кеше әйтте:

- Әгәр берәүнең ашы әзер булган булып, сине ашка өндәр булса, син аны ташлап китмә, - диде.

Шулай итеп, Локман хәкимнең углы өч мең тәңкәсен биреп, өч нәсыйхәтне алганнан соң, сәфәрләрен дәвам иттеләр, янә киттеләр. Бер япанга чыктылар. Ул япанда юлчылар суга гаҗиз булдылар. Чарасыз булып, ахырда бер коега җиттеләр. Ул коеның суы чиксез тирәндә, алырга һич мөмкинчелек юк, кем төшсә дә чыгарга һич әмәл юк иде. Ул мосафирлар төшеп су алырга һич кешене тапмадылар. Аннан соң хәкимнең углын, ихтыярына карамастан мәҗбүр итеп, коега күтәреп салдылар:

- Безгә су алып бир! - диделәр.

Коеның төбенә җиткәч, Локманның углы күрде: бер күркәм гүзәл егет белән кыз утыралар, каршыларында күзләрен алартып бер бака утыра. Кое төбендәге егет Локман углынан:

- Бу кыз белән баканың кайсы яхшырак? - дип сорады.

Угыл: “Кыз яхшырак”, - дип әйтергә теләгән иде, теленнән бу сүз ычкынмас борын шундук мең тәңкәгә алган нәсыйхәте исенә төште. Аннан соң әйтте:

- Синең күңелең кайсын теләсә, шунысы яхшырак.

Ул гүзәл әйтте:

- И егет! үзеңне һәлакәтлектән коткардың, синең кебек күпләр бу урында бу сүзгә җавап таба белми һәлак булдылар.

Аннан соң ул Локманның углына җавапны дөрес әйткәне өчен, бер кызыл алтын бирде һәм су алырга ирек бирде.

Янә киттеләр. Бер шәһәргә килеп керделәр. Ул шәһәрнең хуш табигатьле бер падишаһы бар иде. Локманның углы падишаһка бик ошады: һәр эшне бу улганга әмер итсә, тәмам җиренә җиткереп эшләр иде.

Көннәрдән бер көнне падишаһ, үзенең гаскәре белән сәйранлыкка киткән вакытында, һәммә мал вә милкен Локман углына тапшырып китте.

Падишаһ киткән заманда падишаһның бер яшь хатыны (ул Локман углына мең җан гашыйк иде) янына килде:

- Минем теләгемне үтә, - дип, тиешсез эшкә кыстый башлады. Бу Локманның углына Иблис ләгыйнь вәсвәсә итеп, харам эшкә ният иткән заман, югарыдагы әткәсенең васыятен һәм мең тәңкәгә сатып алган нәсыйхәтен исенә төшереп, падишаһ хатынының әмеренә риза булмады.

Шул заман падишаһның хатыны бу егеткә ябышып, тарткалашып шаһ сараеның ишегеннән килеп чыктылар. Алар тарткалашып чыккан вакытта, падишаһ кире кайтып килә иде, бу хәлне турыдан-туры күрде. Падишаһны күрүе белән үк хатыны әйтте:

- Син бу егеткә ышанып, аны үз урының куеп киттең, син киткәч тә, бу егет шулай рисвай итте, - диде, падишаһны ялган сүз белән ышандырды. Падишаһ егеткә чиксез ачуланды, ләкин үзенең камил акыллы булуы аркасында егетне бер очрактан һәлак итүне тиеш күрмичә сабыр итте:

Шулай да хәйлә белән юк итәргә карар кылдылар.

Падишаһ егеткә боерды:

- Син иртә минем бакчама бар, төрле җимешләр һәм чәчәкләр җыеп, миңа китер. - Үзенең бакчачысына исә әйтте: - Иртән-иртүк синең бакча ишегеннән кем аяк баса, син аның башын кисеп, миңа җибәр, - диде.

Локманның углы, падишаһның әмеренә буйсынып, иртән-иртүк бакча тарафына йөз тотты. Юлда барганда үзенең бер иске дустына очрады.

Дусты әйтте:

- И дустым, кая барасың?

- Падишаһның әмере белән бакчага.

Бу егет шаһның әмере кичегә дип ашыга иде, әмма шунда баягы мең тәңкәгә алган нәсыйхәте хәтеренә килде. “Берәүнең нигъмәте әзер булса, аны ашамый ташлап китмә”, дигән өчен, ул дустының чакыруын кабул итте.

Бу егет нигъмәтне ашаган вакытта, падишаһ хатынның ихтыяры, сабыры бетте. Егетне бик күрәсе килеп, аны коткару нияте белән артыннан чыгып йөгерде.

Хатын бакчага аяк басу белән, ялваруына карамыйча, бакчачы аның башын кисеп, падишаһка җибәрде.

Шаһ хатынның башын күргәч тә хәйран калды. Нишләргә белмичә аптырап торганда, ул әмер иткән җимешләр һәм чәчәкләрне күтәреп, Локман углы килеп керде.

Падишаһ әйтте:

- И егет! Бу ни хәл бу: мин сине һәлаклеккә җибәргән идем. синең урыныңа минем хатынымның башын кисеп җибәрделәр?!

Локманның углы башыннан кичкәннәрнең барын да сөйләп бирде. Аннан соң падишаһ, локман углының сүзләрен дөрес табып, аны үзенең якын вәзире итте.

Әлеге кыйссадан безгә хисса будыр: һәркем нәсыйхәтчевәгазьчеләрнең үгет-нәсихәтен кабул итеп, шул канун вә кагыйдәләр буенча йөрсә, Аллаһ Тәгалә ул бәндәсенә һәр ике дөньяда абруйлык бирер.

Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Рәжәб-Шәғбан 2012 миләди йыл**
**1433 һижри йыл.**

| Рәжәб, Шәғбан | Аҙна көндәре | Июнь, Июль | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сығыа | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16 | Шаршамбы | 6 | 4.14 | 5.44 | 14.30 | 21.16 | 22.46 | 00.16 |
| 17 | Кесе йома | 7 | 4.13 | 5.43 | 14.30 | 21.17 | 22.47 | 00.17 |
| 18 | Йома | 8 | 4.13 | 5.43 | 14.30 | 21.17 | 22.47 | 00.17 |
| 19 | Шәмбе | 9 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.18 | 22.48 | 00.18 |
| 20 | Йәкшәмбе | 10 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.19 | 22.49 | 00.19 |
| 21 | Дүшәмбе | 11 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.20 | 22.50 | 00.20 |
| 22 | Шишәмбе | 12 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.21 | 22.51 | 00.21 |
| 23 | Шаршамбы | 13 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.21 | 22.51 | 00.21 |
| 24 | Кесе йома | 14 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.22 | 22.52 | 00.22 |
| 25 | Йома | 15 | 4.10 | 5.40 | 14.30 | 21.23 | 22.53 | 00.23 |
| 26 | Шәмбе | 16 | 4.10 | 5.40 | 14.30 | 21.23 | 22.53 | 00.23 |
| 27 | Йәкшәмбе | 17 | 4.10 | 5.40 | 14.30 | 21.23 | 22.53 | 00.23 |
| 28 | Дүшәмбе | 18 | 4.10 | 5.40 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 29 | Шишәмбе | 19 | 4.10 | 5.40 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 30 | Шаршамбы | 20 | 4.10 | 5.40 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 1 | Кесе йома | 21 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 2 | Йома | 22 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 3 | Шәмбе | 23 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 4 | Йәкшәмбе | 24 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 5 | Дүшәмбе | 25 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 6 | Шишәмбе | 26 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 7 | Шаршамбы | 27 | 4.13 | 5.43 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 8 | Кесе йома | 28 | 4.14 | 5.44 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 9 | Йома | 29 | 4.14 | 5.44 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 10 | Шәмбе | 30 | 4.15 | 5.45 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 11 | Йәкшәмбе | 1 | 4.16 | 5.46 | 14.30 | 21.23 | 22.53 | 00.23 |
| 12 | Дүшәмбе | 2 | 4.17 | 5.47 | 14.30 | 21.23 | 22.53 | 00.23 |
| 13 | Шишәмбе | 3 | 4.17 | 5.47 | 14.30 | 21.22 | 22.52 | 00.22 |
| 14 | Шаршамбы | 4 | 4.18 | 5.48 | 14.30 | 21.22 | 22.52 | 00.22 |
| 15 | Кесе йома | 5 | 4.19 | 5.49 | 14.30 | 21.21 | 22.51 | 00.21 |

■ Ә сез беләсезме?

## Чиксез ана мәхәббәте



Япониядә җир тетрәгәннән соң ишелгән йортларны сүтеп, кешеләрне коткарып йөрүчеләр бер яшь хатынның йорты янында туктадылар. Ишелгән йорт җимерекләрен тикшереп йөргән вакытта сәҗдә рәвешендә яткан бер хатынны күрделәр. Бу ананың башы һәм иң башлары яраланган, тәне суык, ягъни ул үлгән иде. Әмма әлеге ананың күкрәк астында тәрелгән бер әйбере булган. Коткаручылар, ишелгән бинаның ташларын казып, шушы төрелгән әйберне алып ачтылар. Һәм ни гаҗәп: бу төргәктәге әйбер ананың баласы булып чыга. Һәм тагын да гаҗәбрәге: бу бала исән була. Әлеге өч айлык бала, әйтерсең, бер әйбер дә сизмәгән кебек тыныч кына йоклап ята. Җир тетрәнү башланганнан соң бу ана, сабыен коткару өчен, гәүдәсе белән аны каплап куйган була. Үзе исә яраланып үлә. Бала белән бергә төрелгән кәрәзле телефоны да килеп чыга. Коткару эшләрендә катнашкан кешеләр, әлеге телефонга язылган язуны бер-берсенә биреп укып еладылар, чөнки анда: “Балам, исән калсаң, бел: мин сине бик яратам!” - дип язылган була.

# УРАЗА

Ураза зур әһәмияткә ия. Ул баерак кешеләргә тормыш кыйммәтләрен башкачарак күзалларга һәм үзе күрсәткән шәфкатьлелекнең әһәмиятен тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Аллаһы Тәгалә аңа бу дөньяда мал-мөлкәт, байлык биргән. Ярлы кеше боларга ия түгел. Байлыкка ия булучы моның өчен Үз Раббысына телдән генә түгел, ә юмартлыгы, тән гыйбадәте белән дә шөкерләрен әйтергә тиеш. Аллаһы Тәгалә аның шушы тырышлыкларын күрсә, аның байлыкларын тагын да арттыра. Моңа гарантия булып Коръән Кәримдәге: “Раббыгыз сезгә белдерде: “Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, нигъмәтемне сезгә арттырырмын. Әгәр дә кәферлек кылсагыз, Минем газабым бик каты”, - дигән аять тора. Ашаудан һәм эчүдән тыелып, хәлле кеше мохтаҗ туганнарын, танышларын искә төшерә. Аларның хәлен аңлау аны байлыгы белән уртаклашырга этәрә. Аллаһы Рәсүле Рамазанда ярлыларга ярдәмен көчәйтә иде. Кем дә кем тәне белән генә түгел, ә күңеле, рухы белән ураза тота - ул чын-чынлап ошбу гыйбадәт аша Аллаһы Тәгаләгә якынаерга омтыла.

Ураза гыйбадәте үз-үзеңә хуҗа булырга өйрәтә. Әгәр кеше үз нәфсесе кушканнар буенча гына яши башласа, ул һәлак булачак.

Ураза кешене үз-үзең белән канәгать булудан, тәкәбберлектән коткара. Болар бик зур гөнаһлар. Аллаһы Тәгалә әйтә: “Җир өстендә зураеп күкрәк киереп йөрмә. Чөнки син никадәр зурайсаң да җирне ертырга хәлеңнән килмәс. Һәм никадәр генә зурайсаң да, таулар хәтле зурая алмассың” (17-37). Мохтаҗ булганда кешедә тәкәбберлек сирәк була. Әмма кайберәүләр, әгәр байлыкка ия булсалар, ул байлыкны кем биргә хакында уйламыйча, тәкәбберләнә башлыйлар.

Ураза мөселманны шәйтан йогынтысыннан саклый. Уразада булучы көнозон үзен тыныч тотарга омтыла, юкка-барга кызып китми, көчле дәрт-теләкләргә иярми.

Ураза организмга төрле яклы файда китерә. Ураза вакытында ашкайнату системасы ял итә, эчәгеләр зарарлы калдыклардан чистара, нерв системасы тынычлана. Ягъни ураза кеше рухын гына түгел, аның тәнен дә чистарта. Бу ураза гыйбадәтенең бер хикмәте.

Аллаһы Тәгалә Үзенең киң рәхмәте илә ураза тотучыларга зур бүләкләр әзерләде: ошбу айда изгелек кылучылар һәр хәерле эш өчен савапны башка айларга караганда 10, хәтта кайбер очракларда 700 мәртәбә күбрәк алалар. Пәйгамбәребез (с.г.с.) әйтте: “Әгәр дә кемдә булса Исламны кабул итсә һәм гыйбадәтләрне тиешенчә башкарса, Аллаһы Тәгалә аның элегерәк кылган барлык гонаһларын гафу итәр. Шуннан соң аңа әҗер-савап шул рәвешчә булачак: һәр кылган хәерле эше өчен ул 10 мәртәбә, хәтта 700 мәртәбәгә күбрәк”. Менә ни өчен Рамазан аеның килүе күңеле белән изгелеккә, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә омтылучы, кылган гонаһлары өчен үкенүче һәркем өчен зур бәхет, сөенеч.

Шәригатебез буенча, бәлигълык яшенә җиткән, үз акылында булган, сәламәтлеге мөмкинлек биргән һәр мөселман Рамазан ае уразасын тотарга тиеш. Ураза яңа ай күренгәч кенә фарызга әйләнә. Икенсе шарт - уразага керүче Аллаһы ризалыгы өчен ураза тотарга ният итүен күңеленнән расларга тиеш. Бу эшне таң атканчы үтәү кирәк. Ниятсез ураза уразадан китми.

**Рамазан аенда түбәндәгеләрне эшләү хәерле:**

*Таң атканчы сәхәр ашау. Аны таң беленүгә таба калдыру хәерлерәк. Пәйгамбәребез (с.г.с.) әйтә ки: “Таң алдыннан ашагыз. Чөнки таң алдыннан ашау-эчү хәерле”. Әгәр иртәнге аш вакытында азан тавышы ишетелсә, ураза тотучы азан беткәнче сәхәрне тәмамларга тиеш. Ә ифтарны исә Аллаһы Рәсүле сузмаска кушты. Кояш баю белән җимеш яки су илә авыз ачыла. Ахшам намазыннан соң ифтар мәҗлесе үтә. Ифтар кылгач шул дога укыла: “Аллаһуммә ләкә сумту вә бикә әәәмәнту вә галәйкә тәвәккәлту вә галә ризкыйкә әфтарту, фәгфирлий яәә гаффәру мә каддәмту вә мә әххарту”.*

**Тәрәвих намазын уку.** Ошбу намазны мәчеттә җәмәгать белән үтәү хәерлерәк. Безнең Әбү Хәнифә мәзһәбендә ул 20 рәкәгать укыла. Тәрәвихны ашыгып уку хупланмый. Ирләр белән аралашмаган очракта тәрәвих намазларына хатын-кызларга да йөрү рөхсәт ителә.